ISSN 0868-4545

№ 2. 2011

САЛАВАТ КҮПЕРЕ

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ CHILDREN'S MAGAZINE





БӘЙРӘМ БЕЛӘН!

С ПРАЗДНИКОМ!

CONGRATULATION!

Екатерина патшабикә каретасы



Дускай, синең Казанда Бауман урамы буйлап йөргәнең бармы? Әгәр йөргән булсаң, әкиятләрдә генә очрый торган матур бизәкле каретаны күрми калмагансыңдыр дип уйлыйм. Бу — Екатерина патшабикә каретасы. Әйе, әйе! Чын патшабикәнеке!

Екатерина патшабикә Казанга 1767 елда килә. Аны бик зурлап каршылыйлар. Ул килеп киткәннән соң, шәһәрдә бик күп яңа мәктәпләр, мәчетләр, заводлар төзелә. Казанны «Россия империясенең көньяк башкаласы» дип атый башлыйлар.

Екатерина патшабикәнең чын каретасы Татарстанның дәүләт музеенда саклана. Ә Бауман урамындагы бакыр карета — шуның төп-төгәл күчермәсе. Бу каретага утырып күпләр фотога төшәргә ярата. Гаҗәп бит — кемнең үзен чып-чын патша итеп тоясы килми! Ә синең?

© «Салават күпере», 2011 ел





Бауман урамы буйлап ШҮРКӘ сәяхәт итте.

Игътибар! Яңа бәйге!

РӘСЕМГӘ ИГЪТИБАР БЕЛӘН КАРА ҺӘМ ИСЕҢӘ ТӨШЕР: СИНЕҢ АНЫ «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НЕҢ КАЙСЫ САНЫНДА КҮРГӘНЕҢ БАР? ДӨРЕС ҖАВАП БЕЛӘН БЕРЕНЧЕ ХАТ ҖИБӘРҮЧЕГӘ МАХСУС БҮЛӘК – 2011 НЧЕ ЕЛНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА БУШЛАЙ «САЛАВАТ КҮПЕРЕ» ЖУРНАЛЫ!!!

РӘСЕМНЕ ТИЕШЛЕ ТӨСЛӘР КУЛЛАНЫП БУЯП БЕТЕР.

УҢЫШЛАР СИҢА!!!

1
2
3
4
5
6
7
8

Кышкы могҗиза

Зиннур ХӨСНИЯР



Шүркә урамга чыкты. Көн ямьсез, караңгы. Ишегалдындагы агач башыннан елаган тавыш ишетелде – нәни песи баласы икән. Менүен менгән дә, хәзер төшәргә куркып елап утыра. «Мин сине коткара алмам шул, песи, агач бик биек!» – дип уйлады Шүркә һәм кардан Кыш бабай әвәли башлады.

Менә берзаман көн яктырып китте. Шүркә аптырап күккә карады, кояш та чыкмаган бит, югыйсә?

– Шүркә, хәерле көн! – дип дәште арттан кемдер. Күрше кызы Елмай икән. «Кара, Елмай урамга чыгуга көн яктырып китте бит!» – дип аптырап уйлады Шүркә, тик моны кызның үзенә әйтмәде...

Агач башындагы нәни песи тавышын Елмай да ишетеп алды.

– Абау, песи баласы! Ничек төшә инде ул аннан хәзер?! – дип моңсуланды Елмай. Кызның бу сүзе малайга бик нык тәэсир итте: «Ничек төшсен, мин алып төшәм!» – дип уйлады ул.

Шүркә җәһәт кенә агач башына менеп китте. Тиздән нәни песи баласы кызның кулында җылына иде инде.

– Син бик көчле! Рәхмәт! – диде Елмай Шүркәгә.

– Ә син тылсым көченә ия! – дип куйды Шүркә. – Син булмасаң, ул әле һаман агач башында елап утырган булыр иде!

Бу сүздән икесе дә көлешә башладылар. Елмайның көлүе дә бик матур шул!

– Син көлгәч, буран да туктады, көн дә матураеп китте! – диде Шүркә түзмичә.

– Мин көлгәндә агач ботакларыннан бары карлар гына коела!..

Бу сүздән соң Елмай янә үзенең матур тавышы белән көләргә кереште.

– Карале, кара! – диде Шүркә, күккә күрсәтеп. – Салават күпере чыкты түгелме соң?! Нинди могҗиза!!! Кышкы могҗиза бит бу, әйеме?

– Кыш көне... Салават күпере?! – Елмай аптырап күккә карады, тик бернинди Салават күпере дә күрмәде ул анда... Шуннан соң Шүркәгә:

– Син матурлыкны күрә беләсең! Чын егет кеше син! – диде.

Елмай исемле кызның йөзендәге яктылык һәм күзендәге нурлар, күктә чагылып, бар җиһанны бизи иде. Шүркә исемле батыр малай әнә шуны күргән икән.



Рәссам Әлфия Йосыпова

ДУСКАЙ! ШҮРКӘ ИСЕМЛЕ МАЛАЙ БЕЛӘН ЕЛМАЙ АТЛЫ КЫЗ БЕР-БЕРСЕННӘН КАЙСЫ ЯКЛАРЫ БЕЛӘН АЕРЫЛА? АЛАР АРАСЫНДА НИНДИ ХИС БАРЛЫККА КИЛӘ?

СИН 14 НЧЕ ФЕВРАЛЬ КӨННЕ БУЛАЧАК «ХАЛЫКАРА ГАШЫЙКЛАР КӨНЕ»НӘ ВАЛЕНТИНКАЛАР ӘЗЕРЛӘДЕҢМЕ? АЛАРНЫ КЕМГӘ БҮЛӘК ИТӘЧӘКСЕҢ? ҮЗЕҢ КЕМНӘН КӨТӘСЕҢ?

СИНЕҢЧӘ, МӘХӘББӘТ ХИСЕ БАРЫ ЕГЕТЛӘР ҺӘМ КЫЗЛАР АРАСЫНДА ГЫНА БУЛАМЫ? УЙЛАП КАРА...



Һәрвакыт

Сценарий

Балалар бакчасындагы бүлмә урман аланы рәвешендә бизәлгән. Тамчы тамган тавыш ишетелә, матур көй агыла. Бераздан аланга балалар килеп чыга.

1 НЧЕ БАЛА: Ни булды соң бу?! Күктә кояш көлә, тамчылар тама, һавада хуш исләр сизелә... Ә чәчәкләр үзләре юк.

2 НЧЕ БАЛА: Чыннан да! Әниләр бәйрәме җиткәндә умырзая, нәркис, лаләләр инде уянган була иде бит...

3 НЧЕ БАЛА: Бәлки, икенче аланда очратырбыз аларны? Чәчәкләр узган язда әниләр бәйрәменә уянып өлгерергә сүз биргән иделәр!

Ашыга-ашыга урман эченә кереп китәләр. Шомлы көй яңгырый. Аланга ике яктан Сак белән Сок булып киенгән балалар чыга. Алар бер-берсенә якын килә алмыйлар, шуңа агач артына яшеренеп сөйләшәләр.

САК: Күрдеңме, балалар килеп тә җитте. Алар чәчәкләр эзли.

СОК: Әйе. Чәчәкләрне без яшереп куйганны белми әле алар. Таба алмыйча, буш кул белән кайтып китәчәкләр хәзер. Хи-хи-хи... *(Усал көлә).*

САК: Шул кирәк аларга! Без ничә ел шушы кара урманда яшибез. Берәүнең дә безнең хакта борчылганы юк. Явыз сихердән безне коткарырга теләүче дә юк. Алар чәчәкләр эзләп килгәннәр имеш... Бик ачуым килсә, куып кайтарырмын әле үзләрен! У-у-у-у! *(Куркыныч аваз белән улый).*

Аланга балалар йөгереп керә.

1 НЧЕ БАЛА *(як-ягына каранып):* Нинди тавыш бу?!

2 НЧЕ БАЛА *(шомланып):* Бу урманның сихерле булуын ишетеп белә идем. Әллә дөрес сүз инде?! Чәчәкләрне дә тапмадык... Әллә соң кайтырга чыгабызмы?

3 НЧЕ БАЛА: Дусларым, туктагыз. Мин бу тавышны таныдым. Сак белән Сок тавышы бит бу! Алар турында ишеткәнегез юкмы әллә?

БАЛАЛАР *(куркуга калып):* Юк. Ә кемнәр алар?

3 НЧЕ БАЛА: Алайса, тыңлагыз: яшәгән ди ике малай. Алар әниләренең бер сүзен дә тыңламаган. Әниләре тәмам аптыраган, йөдәгән. Көннәрдән беркөнне, бик нык ачуы килгәч, ул аларны каргаган. Шуннан ике улы да, кошка әверелеп, урманга очкан. Алар һаман да бер-берсе белән кавыша, өйләренә кайта алмый интегәләр ди...





Луиза ЯНСУАР

Булсын әни!



1 НЧЕ БАЛА: Абау, бигрәк куркыныч! (*Шулчак агач артында кыштырдаган тавыш ишетелә*). Әй... Кем бар анда?

Аланга ике яктан Сак белән Сок килеп чыга.

САК *(ачу белән):* Бу — безнең урман! Сез монда нишләп йөрисез?!

БАЛАЛАР *(артка чигенеп):* Без... Без чәчәкләр эзләп килгән идек...

СОК: Бирмибез! Алар — безнең урман чәчәкләре!

3 НЧЕ БАЛА: Ай-яй, усалланмагыз инде! Сез, безне куып җибәргәч, тагын ялгыз калачаксыз бит. Бәлки, без сезгә ярдәм итә алырбыз?

Сак белән Сок бу сүзләрдән соң аптырап кала.

САК БЕЛӘН СОК: Ярдәм итә? Тик ничек?!

БАЛАЛАР: Хәзер бергәләп уйлап табабыз! *(Үзара сөйләшә башлыйлар).*

САК БЕЛӘН СОК: Ярдәм итегез безгә, зинһар! Без сезгә чәчәкләрне кайда яшергәнебезне әйтер идек! *(Агачлар арасыннан яшерелгән чәчәкләрне җитәкләп алып чыгалар).*

1 НЧЕ БАЛА: Уйлап таптым! Сихерне кайтарыр өчен сез әниегезгә багышлап җыр җырларга, йә шигырь сөйләргә тиешсез. Тик бу шигырьдә һәм җырда гел матур сүзләр генә булырга тиеш!

САК: Сөйлим, сөйлим! Мин шигырь сөйлим! *(Мәсәлән, Р. Миңнуллинның «Әни кирәк» шигырен укый).*

СОК: Ә мин җырлыйм! *(Мәсәлән, Г.Зәйнашева сүзләренә Ф.Әхмәдиев иҗат иткән «Кояш гомере» җырын башкара).*

Җыр беткәч, Сак белән Сок канатларын салып ташлыйлар. Аландагы балалар сөенеп кул чабалар.



2 НЧЕ БАЛА: Урррa! Без явыз сихерне җиңдек!

САК БЕЛӘН СОК: Рәхмәт сезгә! Без бүгеннән әнинең сүзен тыңларга, акыллы, ярдәмчел булырга вәгъдә итәбез!

3 НЧЕ БАЛА: Әйдәгез, әниләрне, әбиләрне, апаларны котларга ашыгыйк!

БАЛАЛАР, САК, СОК, ЧӘЧӘКЛӘР: Әйдәгез!

Залда утырган әниләрен, әби-апаларын бәйрәм белән котлыйлар, аларга бүләкләр тапшыралар. Бу вакытта чәчәкләр «Һәрвакыт булсын кояш!» көенә җырлый-җырлый әйлән-бәйлән бии.





Беренче кар

Урамда саф һава,
Беренче кар ява.
Мамык күк карлардан
Бар дөнья агара.
Шатлана балалар
Беренче ак карга.
Көрт, таулар да булыр –
Чанада шуарга.



Җыелып без бергә
Таулардан шуарбыз.
Кошлар күк очарбыз,
Җилләрне узарбыз.
Яу, әйдә, яу син, кар,
Бар дөнья агарсын!
Бизәлсен табигать,
Кешеләр шатлансын.

Әмир ӘХМӘТШИН, 10 яшь.
Бибай Чаллы, Әлки.



Бал кортлары һәм Кеше

Борын-борын заманда бал кортлары урманда агач куышларына оя корып яшәгәннәр. Беркөнне урманга бер абзый килгән. Ул кортларның ояларын күргән дә, аларга озак карап торган: «Бу кортларга агач куышындагы өйләрдә яшәү бик уңайсыздыр инде. Боларга оя ясыйм әле», – дип уйлаган.

Берничә көннән оя әзер булган. Абзый аны матур төсләргә буяп урманга алып килгән һәм кортлар башлыгына әйткән:

– Мин сезгә яңа йорт ясап алып килдем. Әгәр ошатсагыз, шунда яшәрсез.

Кортлар башлыгы оя эченә кереп карап чыккач:

– Бик зур рәхмәт, өй шундый матур булган. Без сиңа нинди яхшылык эшлик? – дигән.

– Сез шундый бәләкәй, миңа нинди эш булдыра алырсыз икән соң? – дип уйга калган абзый.

– Ә син безнең янга бер ай үткәч кил, – дип җавап кайтарган бал кортлары башлыгы.

Бер ай вакыт тиз узып киткән. Абзый бал кортлары янына килгән. Бал кортлары башлыгы аңа бал сузган һәм:

– Менә авыз итеп кара әле, тәмлеме? – дип сораган.

–Тәмле, – дигән абзый.

Шуннан бирле бал кортлары кешегә бал җыя, ә кешеләр аларга матур өйләр ясый башлаган.



Айзилә СӘХӘБИЕВА.
Югары Чаллы, Түбән Кама.





Роберт МИҢНУЛЛИН

Әни, мин көчек күрдем!

Әни, мин уйнаганда
Көчек күрдем урамда.
Әни, ул туңган иде,
Урамда кунган иде.
Әни, салкын яңгырда
Ул бик күшеккән иде,
Ул бик ачыккан иде
Һәм бик талчыккан иде.
Әни, ул улый иде,
Ул шулай елый иде,
Ул чынлап елый иде.
Ул ныклап елый иде.
Мин аны бик кызгандым –
Яшьләре ага иде.
Әни, аның яшьләре
Асфальтка тама иде.
Аны, әни, яңгырда
Кемдер ташлап калдырган,
Алдаштырып калдырган,
Адаштырып калдырган...
Әни, туңганга микән,
Ул бик дерелди иде.
Салкын тисә, ул көчек
Тышта терелми инде.
Нишләр инде ул анда,
Бер ялгызы урамда?
Ул елыйдыр әле дә,
Дерелдидер тәне дә.
Иртәгә ул үләчәк,
Калдырсаң бу хәлендә.

Әнием, шул көчекне
Алып керик, ә?

Мама, я видел щенка!

Я на улице играл,
Встретил маленький комочек –
Это был простой щеночек,
На асфальте он лежал,
Мама, он там ночевал,
Весь озяб в холодный дождь.
Он голодный, он устал,
Видно было его дрожь;
Он так плакал, так скулил,
Что пройти не мог я мимо;
Дождь беспрестанно лил,
Приближая злую зиму...
Кто с ним мог так поступить?
Обмануть и заблудить!
Он же быстро заболеет,
Уж не сможем излечить.
Будет плакать и дрожать,
До утра не доживет.
Давай поможем мы щенку,
К себе его возьмем, пойдет?

Роман СӘЛАХЕТДИНОВ тәрҗемәсе.
7 нче сыйныф, 15 нче мәктәп, Казан.










1

Уң яктагы рәсем кисәкләрен эзләп тап.

Чаңгычы куянны төрле төсләргә буя.



2

Рәсемдә кышкы һәм җәйге киемнәр буталган. Тәртип урнаштырыр өчен кышкы киемнәр шакмагын зәңгәр, ә җәйге киемнәрнекен кызыл төскә буя.

Дөрес парны тап.



3







«БУ – МИНЕМ ДӨНЬЯ»

НОМИНАЦИЯСЕНДӘ:





Әлфинур ШӘРӘПОВА

Айсылу ХАФИЗОВА

Камилә БИКТИМЕРОВА

АКТАНЫШ РАЙОНЫ УСЫ БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘБЕНЕҢ 1 НЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫ.

«КАДЕРЛЕ КЕШЕМ»

НОМИНАЦИЯСЕНДӘ:

«МИНЕМ БУЛАЧАК ҺӨНӘРЕМ»

НОМИНАЦИЯСЕНДӘ:



Илфак ЗАКИРОВ



Нурислам НАЗЫЙМОВ

Шаян чәчәкләр



Дускай, белгәнеңчә, тиздән 8 нче март — Халыкара хатын-кызлар көне!
Бу көнне без, әби-әниләребезгә, апа-сеңелләребезгә, дус кызларыбызга матур сүзләр әйтеп, бүләкләр ясап, янә үз мәхәббәт-хөрмәтебезне күрсәтә алабыз!
Ә иң затлы бүләк — чәчәкләр бәйләме...




КИРӘКЛЕ ӘСБАПЛАР:

- ваза
- агач таякчыклар (чәчәк сабагы)
- төрле төстәге төймәләр (чәчәкнең уртасы)
- фетр, бәрхет яисә катыргы кәгазьдән киселгән чәчәк нигезләре
- яшел тасма (яфраклар)
- энә белән җеп



1

Төрле зурлыктагы һәм төстәге чәчәк нигезләрен, кечесен зуррагына туры китереп, уртага төймә куеп, энә белән җеп алып тегәбез.



2

Һәрбер чәчәккә агач таякчык беркетәбез.



3

Яшел төстәге тасмаларны агач таякчыкка матур итеп бәйләсәк, чәчәк сабагында яфраклар да пәйда булачак.



4

Ясаган чәчәкләрне бергә җыеп, вазага урнаштырабыз һәм бүләгебез әзер!!!

Иң мөһиме — кадерле кешеңә бүләк биргәндә матур сүзләр әйтергә онытма!







Дускай! 23 нче февраль – Ватанны саклаучылар көне. Бу көнне әтиеңне, абыеңны, энекәшеңне һәм башка ир туганнарыңны тәбрикләргә онытма! Бәйрәм белән сине!

Шәүкәт ГАЛИЕВ

Бусы – хәрби сер!

Еракта-еракта тора,
Минем абый сакта тора.
Әни эштә чакта тора,
Әти юлда чакта тора,
Мин уйнаган чакта тора,
Син йоклаган чакта тора!

Телевизор да карамый,
Читкә карарга ярамый,
Чиккә генә карап тора,
Дошман килеп кермәсен ди,
Безнең серне белмәсен ди.

Әниләр эштә булганда
Берүзең генә калганда,
Түгел өйне саклап тору,
Бу бит – илне саклап тору!

Еракта-еракта тора,
Минем абый сакта тора.
Сакта һәр-һәр чакта тора.
Әйтмим кайсы якта тора,
Син үзең дә сорап торма,
Бусы – хәрби сер!



Военная тайна!

Далеко-далеко-далеко
Старший брат мой в дозоре стоит.
Мама доит коров – он стоит,
Папа где-то в пути – он стоит,
Я играю в футбол – он стоит,
Ты в кроватке сопишь – он стоит.

Телевизор смотреть не велят,
Головою вертеть не велят,
Вдоль границы скользит его взгляд,
Чтобы враг мимо не прошмыгнул,
Нашу тайну чтоб не умыкнул.

Вахте брата не ровня твой труд:
Когда мама и папа уйдут,
Дом стеречь оставляя одну –
Стережёт он большую страну!

Далеко-далеко-далеко
Старший брат мой в дозоре стоит.
Каждый день, каждый миг он стоит,
Я тебе не скажу, где стоит,
Не скажу, где сейчас он живёт –
Это тайна военная, вот!

A Military secret!

Far-far away
My brother is on guard.
While mom is at work,
While dad is on the way,
While I sleep or I play,
My brother is on guard.

He doesn't watch TV,
He doesn't look aside.
He only guards the border,
Not to allow enemies
Violate the border
And reveal our secret.

When my parents are at work,
I'm alone at home,
This is not protecting house,
This is guarding motherland!

Far-far away
My brother is on guard.
I won't tell you where he is,
Because this is
Our military secret!

Русчага Наил ИШМӨХӘММӘТОВ,
инглизчәгә Илмир ИЛАЙ тәрҗемә итте.

Рәссам Светлана ИБРАҺИМОВА



Биш дус

Зилә ЯЗ

Яшәгән ди, булган ди биш дус – Елмай, Шалай, Шүркә, Йомшаккай һәм Салават күпере кошы – Матуркай. Дус булсалар да, дуслыкны һәрберсе үзенчә аңлый икән алар.

Елмай тәмле телле, дусларына гел матур сүзләр белән эндәшә:

– Киемең бик килешле, елмаюың сөйкемле, – дияргә ярата ул.

Йомшаккай исә дусларына төрле бүләкләр өләшергә маһир. Ул аларга үзе уйлап чыгарган җайланмалар, кызыклы китаплар бирергә гадәтләнгән. Шул рәвешле үзенең дуслыгын белдерә икән.

Шүркә исә, дусларын сагынса, җыена да, аларның күңелләрен күтәрергә китә. Берәрсе аңа:

– Синсез беркая да бармыйбыз, синсез күңелсез, – дисә, урман малаеның түбәсе тәмам күккә тия инде.

Ә Шалай дусларына карата гел ярдәмчел булырга тырыша. Шулай бервакыт Йомшаккайның:

– Математикадан бер мисалны чишә алмыйм, – диюен ишеткәч, ул беренче булып ярдәмгә килде.

Беркөнне Матуркай дусларын туган көненә чакырды. Кунаклар килер алдыннан ул өйне әйбәтләп җыештырды, күп итеп тәмле ризыклар пешерде. Дуслары килгәч:

– Тортка җитешегез, чәйне кәнфит белән эчегез, әнә, туңдырма белән дә сыйланыгыз...Тагынниләр алып килим? – дип, йөгерә-йөгерә кунакларын сыйлады.

Елмай Матуркайга:

– Син бүген тагын да матуррак күренәсең! –диде.

Йомшаккай:

– Матуркай, менә сиңа миннән бүләк! – дип, бик кыйммәтле ярма савыты тартып чыгарды.

Шүркә исә Матуркай яныннан бер дә китмәде, аның күңелен күтәрергә тырышты. Ә киткәндә, барысы берьюлы:

– Без бүген көне буе бергә булдык, без – чын дуслар! – диделәр.

Шалай да, үз дуслыгын белдерергә теләп, Матуркайга:

– Булышырга кирәк булса, әйтерсең, – дип өстәде.

Тик Йомшаккай гына, бер сүз әйтмичә, дустына булышырга калды.




Рәссам Евгения ГЛЕБАШЕВА
Синең өчен дуслык нәрсә ул?
Биш дусның кайсысы чын дус? Ни өчен шулай уйлыйсың?
«Йөз сумың булганчы, йөз дустың булсын» дигән мәкальне ничек аңлыйсың?
15
ӘКИЯТ-ТЕРАПИЯ



SKворд







«Сөйкемле йөз»



Айзирә, 6 яшь

Кыш килгәнен сиздем мин,
Ап-ак туным кидем мин!


Кама Тамагы, Келәнче.



Илгизә

Ит тарткыч һәм кавын әзер –
Эшкә керешәбез хәзер!

Актаныш, Ахун.



Гөлгенә, 9 яшь

Аягымда – күрегез! –
«Һау-һау» ди кем? Белегез!

Актаныш, Ахун.





Ралина, 6 яшь

Җырчылардан кай җирем ким?
Алкышлагыз – чын «йолдыз» мин!

Актаныш, Аккүз.

№2(251) – 2011

Журнал 1990 елның
март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит
с марта 1990 года.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир
урынбасары
Зилә ЯЗ

Бүлек мөхәррирләре
Ләбиб ЛЕРОН
Римма ШӘЙДУЛЛИНА
Луиза ЯНСУАР

Бизәлеш мөхәррире
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисапчылар
Рәмзия САЛИХ
Лилия ӘХМӘТҖАНОВА

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече
яшьтәге мәктәп балалары өчен.
«Салават күпере» журналының
компьютер үзәгендә җыелды һәм
төсләргә бүленде.
Басарга кул куелды 26.2.2011 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура - Букварь. Офсет ысулы
белән басыла. Заказ Р-68.
Тираж 10858 данә.



Журналны гамәлгә куючы -
«Татмедиа» ачык акционерлык
җәмгыяте.



Тираж сертификацияләнгән.
Бәясе килешү буенча.
Индекс 73953.

Тышлыкта Булат ГЫЙЛЬВАНОВ
рәсеме.

Безнең адрес: 420066, Казан ш.,
Декабристлар ур., 2 нче йорт.
Тел.: (843) 222-09-86, 519-45-82.
E-mail: salavatkupere@mail.ru

Татарстан Республикасы Мәгълүмат
һәм матбугат министрлыгы
тарафыннан 321 номер белән 1994
елның 4 февралендә теркәлде.
«Татмедиа» ачык акционерлык
җәмгыяте филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексында
басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар
ур., 2 нче йорт.

Йолдызнамә

Сукояр

21 нче гыйнвар – 20 нче февраль. Әйе, нәкъ менә шушы вакытка синең туган көнең туры килә, кадерле Сукояр-дускай!

Синең яхшы якларың, матур һәм уңай сыйфатларың шактый. Мәсәлән, син бик аралашучан, шук-шаян. Яңа танышлар белән тиз арада дуслаша аласың. Яшьтәшләрең сине ярата, хөрмәт итә. Юк кына нәрсәдән дә кызык табасың. Хыялыйлыгың, әкәмәт әйберләр, төрле уеннар уйлап табарга маһир булуың белән янәшәдәгеләрне һәрдаим шаккатырып торасың. Үзеңне һәркайда һәм һәрвакыт иркен тотасың. Шулай да, синең байтак кына тискәре сыйфатларың да бар. Кайвакыт үзеңне «Менә ул мин! Күрегез мине!» дигәнрәк рәвештә тотасың. Мактанып, шапырынып алырга да онытмыйсың. Абдулла Алишның әкиятендәге Сертотмас үрдәк шикелле, артыгын сөйләшергә, әйтергә ярамаган кайбер серләрне дөньяга сибәргә дә яратасың. Еш кына бу сыйфатың аркасында үзеңне дә, якыннарыңны да, дусларыңны да кыен хәлгә куясың. Үзеңә кушылган эшләргә җавапсыз караган чакларың да, әңгәмәдәшләрең белән дорфа сөйләшкән вакытларың да булгалый.

Шулай да, Сукояр-дускай, син үзеңнең кемлегеңне, нинди икәнлегеңне бик яхшы аңлыйсың. Янәшәңдә беркем булмаганда да, син үзеңә шөгыль таба беләсең. Әйтик, «Салават күпере»н укыганда, мавыгып китеп, журналдагы шаян дусларың Шалай, Шүркә, Йомшаккай һәм Елмай белән бергә хыялый маҗаралар уйлап чыгарырга мөмкинсең. Гел шулай шат күңелле, тапкыр, зирәк, акыллы булып кал, яме, Сукояр-дускай!



Рәссам Сергей ЕЛИСЕЕВ

